## КАРАР

“ 24» ноябрь 2025 ел № 13

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Мөрәле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары,

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Мөрәле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 800 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1600 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру,транспорт хезмәтләре);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешен вак таш белән өлешчә тигезләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһаз чапкыч сатып алуны финанслашу ); балалар мәйданчыгы өчен елга комы сатып алу һәм китерү);

- гадәти күмү урыннарын  коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү;
(материал сатып алып китерү, буяу һәм зиратны коймалап алу, зиратны тоту өчен бензинлы чапкыч,бензопила сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважинадан алып су башнясына кадәр суүткәргеч челтәрен урнаштыру);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 184 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 94 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә Мөрәле авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Мөрәле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 800 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1600 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар,

автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру,транспорт хезмәтләре);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешен вак таш белән өлешчә тигезләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһаз чапкыч сатып алуны финанслашу ); балалар мәйданчыгы өчен елга комы сатып алу һәм китерү);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү; (материал сатып алып китерү, буяу һәм зиратны коймалап алу, зиратны тоту өчен бензинлы чапкыч,бензопила сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважинадан алып су башнясына кадәр суүткәргеч челтәрен урнаштыру);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныргга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Мөрәле авылы, Үзәк урам, 41 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин